**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы структурасына үзгәреш кертү турында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы мәсьәләләре» 2008 елның 31 декабрендәге ПУ-713 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2011 елның 31 октябрендәге ПУ-688 номерлы, 2013 елның 26 декабрендәге ПУ-1276 номерлы, 2014 елның 1 сентябрендәге ПУ-829 номерлы, 2016 елның 23 декабрендәге ПУ-1193 номерлы, 2017 елның 29 декабрендәге ПУ-1174 номерлы, 2021 елның 20 гыйнварындагы ПУ-37 номерлы, 2021 елның 30 июнендәге ПУ-528 номерлы указлары һәм Татарстан Республикасы Рәисенең 2024 елның 11 июлендәге 531 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы структурасына, аны кушымтада бирелә торган яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

билгеләнгән тәртиптә әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә;

үз актларын әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче башка карарлар кабул итәргә.

3. Әлеге Указ 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.


**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ · АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2024 ел, 28 декабрь
№ 1036

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2024 елның «28» декабрендәге
1036 номерлы Указына
кушымта

**Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы структурасы**




______________